Татарстан Республикасы

Казан шәһәре Авиатөзелеш районы “134 нче татар-рус урта гомуми белем бирү мәктәбе”

гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе

| **Каралды:** | **Килешенде :** | **Расланды:** |
|---|---|---|
| МБ утырышы беркетмәсе №1<br>МБ җитәкчесе<br>___________ А.Җ. Зәйнуллина<br>Дата 25.08.2015 | Директор урынбасары<br>__________ Н.Б .Мусина<br>Дата 26.08.2015 | Мәктәп директоры<br>__________ А.С.Петров<br>Педагогик совет утырышы беркетмәсе №1<br>Дата 27.08.2015 |

***Эш программасы***

Фән- татар теле

9 нчы “А” сыйныфы, татар төркеме.

Ф.И.О.- Зәйнуллина Альмира Җиһангәрәй кызы, югары квалификацион категорияле

Гамәлдә куллану вакыты- 2015/16 нчы уку елы.

Казан- 2015 -2016 нчы уку елы

**Аңлатма язуы**

**Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелде:**

1. Россия Федерациясе конституциясе 12.12.1993 (РФ Конституциясенә 30.12.2008 елда №6-ФКЗ, 30.12.2008 елда №7-ФКЗ,21.07.2014 елда №11-ФКЗ белән кергән үзгәрешләр исәпкә алынды.
2. Татарстан Республикасы Конституциясе 6.11.1992(үзгәрешләр һәм әстәмәләр белән)
3. .29.12 2012 нче елда кабул ителгән 273 нче номерлы "Россия Федерациясендә Мәгариф турында" Федераль кануны.
4. 22.07. 2013 нче елда кабул ителгән 68 нче номерлы "Мәгариф турында" Татарстан Республикасы кануны.
5.8.07.1992 нче елда кабул ителгән 1560 – XXII номерлы "Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" ТР кануны.
6.. 17.12.2010 елда кабул ителгән 1897 номерлы төп гомуми белем бирүнең(ООО) Федераль дәүләт белем стандарты..
7.ТР Мәгариф министрлыгының 7699/12 номерлы боерыгы, 23.06.2012 ел "Об учебных планах для 1-11 классов школ РТ, реализующих основные образовательные программы начального общего образования и основного общего образования в соответствии с ФГОС общего образования".
8. ТР Мәгариф министрлыгының 9807/12 номерлы хаты, 13.08.2012 ел "О преподавании татарского государственного языка в общеобразовательных учреждениях РТ" һәм №9777/12 номерлы хаты, 13.08.2012 ел "Об изучении татарского языка и литературы в образовательных учреждениях".
9."Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәмәдәбиятыннан үрнәк программалар " 1-11 нче сыйныфлар.
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011 нче ел.
Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова, В,А, Гарипова авторлыгында. (программа федераль дәүләт белем стандартларына (ФГОС) нигезләнеп төзелгән).
10. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгының 2015/2016 нчы уку елында татар телен укыту үзенчәлекләре.Методик тәкъдимнәр.Казан.2014ел
11. СанПиН 2.4.2.2821-10 "Гомуми белем бирү учреждениеләрендә укыту өчен шартлар һәм укытуны оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр" (РФның баш дәүләт санитар табибының 189 нчы номерлы карары. 29.12.2010 ел)
12. Казан шәһәре Авиатөзелеш районы "134 нче татар-рус урта гомуми белем бирү мәктәбе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015/2016 нчы уку елына уку-укыту планы**.**

**Дәреслек:** 9 нчы сыйныфта татар теле дәреслеге. Татар теле. К.З. Зиннәтуллина, Ф.Ф. Фатыйхова, Р.Х. Мирзаһитов - Казан, "Татарстан китап" нәшрияты , 2011.

**Укыту планында 9 нчы сыйныфта татар теленнән атнага 2 сәгать вакыт бирелә, елга 68 сәгать каралган.**

**9 сыйныфта татар теле укытуның максатлары:**
Укучыларда татар теленә хөрмәт һәм аны ярату, рухи кыйммәт һәм кешелек дөньясының аралашу, белем алу чарасы буларак аңлы караш тәрбияләү;
Укучыларның сөйләү һәм фикерләү сәләтен үстерү, аларны татар әдәби телен тормышның төрле өлкәләрендә иркен куллана алырлык шәхесләр итеп тәрбияләү; дөрес сөйләм эшчәнлегенең үзара аралашу чарасы икәнен белдерү;
Татар теле, аның төзелеше, кулланылышы турында мәгълүмат алу; татар әдәби теленең төп нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллау, аларны тиешенчә куллана белү; сүз байлыгын арттыру, сөйләмдә кулланыла торган грамматик чараларны төрлеләндерү;
Телне өйрәнгәндә үзләштергән белем һәм күнекмәләрне сөйләмдә дөрес куллана белү.
**Татар теле укытуның бурычлары:**

**Коммуникатив компетенция.** Сөйләм. Телдән һәм язма сөйләм. Диалогик һәм монологик сөйләм. Сөйләм стильләре. Матур әдәбият теле.

Телдән һәм язма сөйләмне аеру. Тел берәмлекләрен аралашуны ситуация үзенчәлекләренә карап сайлый белү. Аралашу өлкәсенә һәм ситуациясенә бәйле рәвештә телдән һәм язма сөйләмне дөрес файдалану.
Текстның темасы, төп фикере һәм төзелеше. Аларның стильләрендә жанр төрлелеге.
Татар әдәби теле һәм аның нормалары турында төшенчә.
Сөйләм эшчәнлеге төрләрен (тыңлап аңлау, сөйләү, уку һәм язу) үзләштерү.
Укуның төрле төрләрен (танышу, өйрәнү һ.б.)үзләштерү. Уку китаплары, масса күләм мәгълүмат чаралары, интернет һ.б. чаралар белән эшләү алымнарын үзләштерү.
Иҗтимагый-мәдәнии, әхлакый, көнкүреш, уку темаларына бәйле булган монологтк һәм диалогик сөйләм үрнәкләрен төзү.
Текстның эчтәлеген кыскача , тулы яки сайлап алып сөйләү. Диктантлар, изложениеләр һәм сочинениеләр язу. Төрле стилҗ һәм жанрдагы текстлар төзү: бәяләмә, аннотация, хат, ышаныч кәгазе, гариза, тезис, конспект һ.б.ш.

**Лингвистик компетенция.** Телнең кеше тормышында һәм җөмгыятьтә тоткан урыны. Татар теле – Татарстан Республикасының дәүләт теле. Татар теле – татар халкының милли теле.
Матур әдәбият һәм аның нормалары турында төшенчә.
Татар теленең үсештә булуы. Соңгы елларда татар теле лексикасындагы үзгәрешләр.
Тел белеменә караган сүзлекләр һәм алардан файдалану.

**Төп гомуми белем бирү мәктәбен тәмамлаучы укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләренә таләпләр**

*Фонетика:*

1. Сузык һәм тартык авазларның классификациясен, алардагы үзгәрешләрне белү. Сингармонизм законын, рәт һәм ирен гармониясе үзенчәлекләрен сөйләмдә дөрес куллану,
2. Татар телендә иҗек калыплары, сүзләрне дөрес басым белән әйтү. Җөмләләрдә логик басымны дөрес билгеләү, тиешле интонация белән сөйләү.
3. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Алфавитны истә калдыру.
4. Сүзләргә фонетик анализ ясау.
5. Орфоэпик сүзлекләрдән файдалану.

*Лексика һәм фразеология;*

1.Татар теленең сүзлек составының килеп чыгуы, кулланылу өлкәсе һәм кулланылу дәрәҗәсе буенча бәяли белү.
2. Сүзләрне һәм фразеологизмнарны урынлы куллану, аларның мәгънәләренә аңлатма бирә белү. Синоним, омоним, антоним сүзләрне дөрес куллану.
3. Төрле типтагы сүзлекләрдән файдалана белү.

*Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы:*

1. Сүзләрнең мәгънәле кисәкләренә аңлатма бирә белү. Тамырдаш сүзләр табу. Сүзләрне төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерү.
2. Татар телендә сүзләрнең ясалыш ысулларын белү.

*Морфология:*

1. Сүз төркемнәрен лексик-грамматик мәгънәсе, морфологик һәм синтаксик билгеләре буенча аера һәм аларны таный белү. Морфологик анализ ясау.
2. Өйрәнелгән сүз төркемнәре белән җөмләләр һәм текстлар төзү. Сүз төркемнәренең төрле ысуллар белән ясалышын белү.

*Синтаксис:*

1. Сүзтезмәләргә, гади һәм кушма җөмләләргә синтаксик анализ ясый белү.
2. Сүзтезмәне җөмләдән аера белү. Сүз төркеме белән җөмлә кисәген дөрес билгеләү.
3. Аерымланган җөмлә кисәкләре, эндәш һәм кереш сүзләр кергән җөмләләр төзү.
4. Туры һәм кыек сөйләмне дөрес куллану, алар кергән җөмләләр төзү.
5. Кушма җөмләләрнең схемасын төзү.
6. Текстның үзенчәлекле билгеләрен белү. Аның стилен дөрес билгеләү.
7. Җөмләдәге сүз тәртибен билгеләү.

*Пунктуация:*

1. Җөмлә һәм текстта тыныш билгеләре куелырга тиешле урыннарны дөрес табу. Бирелгән җөмлә һәм текстта куелган тыныш билгеләренә аңлатма бирү.
2. Диалог, туры һәм кыек сөйләм янында тыныш билгеләрен куя белү.

*Сөйләм эшчәнлеге:*

1.Укучыларның, үз тәҗрибәләреннән чыгып, диалогик һәм монологик сөйләм оештыра белүе.
2.Укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген сөйләү, планын төзү.
3.Бирелгән план буенча сочинение язу.
4. Әдәби геройларны сурәтләп бирү.
5. Каралган спектакль буенча хикәя төзү (телдән яки язмача).
6. Программа буенча укылган китапның эчтәлеген сөйләү яки язу, үз фикереңне белдерү.
7. Эш кәгазьләре (гариза, белдерү, ышаныч кәгазе һ.б.) язу
8. Якын дустыңа, туганыңа хат язу.
9. Укытучы биргән яки укучы үзе сайлаган китапка аннотация язу.
10. Сочинение элементлары булган изложениеләр язу.
11. Стилистик хаталары булган җөмләләрне яки текстны төзәтү.
12. Татарчадан русчага, русчадан татарчага тәрҗемә итү күнегүләре эшләү.

**Татар теле дәресләрендә ел дәвамында бердәм республика тестларына хәзерлек күздә тотыла.**

## ТАТАР ТЕЛЕННӘН БЕЛЕМ ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘРНЕ БӘЯЛӘҮ НОРМАЛАРЫ:

### Язма эшләрнең күләме

| сыйныф | Эш төрләре | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Соч-е | Диктант | Изл-е | Барлыгы |
| IX | 7 (2) | 5 (2) | 2 (1) | 14 (5) |

Искәрмә: Җәя эчендә контроль характердагы эшләр саны күрсәтелде.

### ДИКТАНТЛАРНЫҢ КҮЛӘМЕ ҺӘМ АНЫ БӘЯЛӘҮ:

1. Орфографик хатасы булмаса, «5” ле куела (бер пунктуацион хата булырга мөмкии).
2. Бер орфографик, бер пунктуацион хатасы булса, “4” ле куела.
3. Ике орфографик, ике пунктуацион хатасы булса, “3”ле куела.
4. Биш орфографик, дүрт-алты пунктуацион хатасы булса, ”2” ле куела.

Өйрәтү диктантлары 5-7 нче сыйныфларда ешрак яздырыла.

**КОНТРОЛЬ ДИКТАНТЛАРНЫҢ КҮЛӘМЕ ҺӘМ АНЫ БӘЯЛӘҮ:**

| IX сыйныф | | | |
|---|---|---|---|
| Уку елы башы | 105-120 | Уку елы ахыры | 115-125 |

Контроль диктант текстлары үз эченә өйрәтелгән тема яки темалар буенча орфограмма һәм пунктограммаларны (2-3 очрак) ала. Грамматик биремле диктант булганда, сүз саны киметелә дә ала. Контроль диктантта укучы тарафыннан төзәтүләр күп булса, билге бер баллга төшәргә мөмкин.

КОНТРОЛЬ ДИКТАНТНЫ БӘЯЛӘҮ

1. Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаса “5” ле куела. (Бер орфографик, ике пунктуацион хата булырга мөмкин.)
2. Ике орфографик, ике пунктуацион яки бер орфографик, дүрт пунктуацион хаталы эшкә “4” ле куела.
3. Дүрт орфографик, дүрт пунктуацион яки өч орфографик, алты пунктуацион хаталы эшкә «3» ле куела.
4. Алты орфографик, биш пунктуацион яки биш орфографик, сигез пунктуацион хаталы эшкә «2» ле куела.

ИЗЛОЖЕНИЕНЕҢ КҮЛӘМЕ ҺӘМ АНЫ БӘЯЛӘҮ:

| сыйныф | Уку елы башы | | Уку елы ахыры | |
|---|---|---|---|---|
| | Сүз саны | Язма күләме | Сүз саны | Язма күләме |
| IX | 350-370 | 135-140 | 370-390 | 140-145 |
| | | | | |

Изложение һәм сочинениегә ике төрле билге куела. Берсе – эчтәлек, сөйләмне дөрес оештыра алу өчен, икенче – грамоталылыкка.

1. Тема тулысынча ачылган, фактик һәм техник хаталары булмаган, стиль бердәмлеге сакланган эшкә «5» ле куела. (Бер орфографик, ике пунктуацион яки ике грамматик хатасы булырга мөмкин.)
2. Текстның эчтәлеге темага нигездә туры килсә, фикерне белдерүдә зур булмаган ялгышлыклар җибәрелсә, бер-ике фактик, бер-ике техник хатасы булса, ике орфографик, ике-еч пунктуацион, бер грамматик хатасы булган эшкә «4» ле куела.
3. Язмада эчтәлек эзлекле бирелмәсә, стиль бердәмлеге сакланмаса, өч фактик, ике-өч техник хатасы булса, өч орфографик, дүрт пунктуацион, ике грамматик хатасы булган эшкә «3» ле куела.
4. Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталары күп булса, орфографик хаталарның саны дүрттән, пунктуацион хаталарның саны биштән, грамматик хаталар саны өчтән артса, «2» ле куела.

## СОЧИНЕНИЕНЕҢ КҮЛӘМЕ ҺӘМ АНЫ БӘЯЛӘҮ:

Әдәби (хикәяләү, очерк, истәлек, хат, рецензия һ. б.), әдәби-иҗади, өйрәтү характерындагы, ирекле, рәсемнәр нигезендә үткәрелә торган һәм контроль сочинениеләр була.

Сочинение план нигезендә языла. Ике сәгать дәвамында сыйныфта язылган *сочинениенең күләме* түбәндәгечә булырга тиеш: 5 нче сыйныфта 0,5—1 бит, 6—7 нче сыйныфларда 1—2 бит, 8 нче сыйныфта 2—2,5 бит, 9 нчы сыйныфта 2,5— 3,5 бит, 10—11 нче сыйныфларда 3,5—6 бит.

1. Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килсә, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлегә сакланса, «5» ле куела. (Бер орфографик яисә ике пунктуацион (грамматик) хата булырга мөмкин.)
2. Язманың эчтәлеге нигездә темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлыклар күзәтелсә, бер-ике фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, ике орфо график, өч пунктуацион (грамматик) яисә бер-ике сөйләм ялгышы булса, «4» ле куела.
3. Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлар, аерым фактик төгәлсезлекләр булса, хикәяләүдә эзлеклелек югалса, сүзлек байлыгы ярлы булса, стиль бердәмлеге дөрес сакланмаган җөмләләр очраса, өч орфографик, дүрт пунктуацион (грамматик) яисә өч-дүрт сөйләм хатасы булса, «3» ле куела.
4. Язма темага туры килмичә, фактик төгәлсезлекләр күп булып, план нигезендә язылмаса, сүзлек байлыгы бик ярлы булса, текст кыска һәм бер типтагы җөмләләрдән торып, сүзләр дөрес кулланылмаса, стиль бердәмлеге сакланмаса, биш орфографик, сигез пунктуацион (грамматик) яисә дүрт-алты сөйләм хатасы булса, «2» ле куела.

Татар урта мәктәпләре өчен татар теле программаларында диктант, изложение һәм сочинение яздыруга куелган таләпләр, нигездә, рус мәктәбендә укучы татар балаларына да туры килә.

## Укыту – методик комплекты

1. ”Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” 1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, Казан, “Татарстан китап” нәшрияты, 2011 ел.
2. 9 нчы сыйныфта татар теле дәреслеге. Татар теле. К.З. Зиннәтуллина, Ф.Ф. Фатыйхова, Р.Х. Мирзаһитов - Казан, “Татарстан китап” нәшрияты , 2011

**Өстәмә әдәбият:**

1.Татар теле морфологиясе. /Ф.М. Хисамова. - Казан, “Мәгариф” , 2005.
2.Хәзерге татар әдәби теле. / Ф.С. Сафиуллина, М.З.Зәкиев.- Казан, “Мәгариф” , 1994.
3.Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. / Ф.С.Вәлиева, Г.Ф. Саттаров. – Казан: “Раннур”, 2000.

***Программаның эчтәлеге***

| № | Төп темалар | Сәг. | Белем һәм күнекмәләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Синтаксис буенча 8 класста өйрәнгәннәрне кабатлау. | 1 | Гади җөмлә синтаксисы; |
| 2. | Кушма җөмлә төрләре. | 25 | -Кушма җөмлә: кушма җөмлә турында гомуми төшенчә, кушма җөмлә төзүче җөмләләрнең бер-берсенә бәйләнеше<br>-Тезмә кушма җөмлә:  тезмә кушма җөмләләрдә бәйләүче чаралар; теркәгечле тезмә кушма җөмләләр, алар янында тыныш билгеләре; теркәгечсез  тезмә кушма җөмләләр, алар янында тыныш биогеләре.<br>-Ииярченле кушма җөмлә: баш һәм иярчен җөмлә; иярчен җөмләләрне мәгънә һәм төзелеш ягыннан төркемләү.<br>-Иярченле кушма җөмләнең төзелеш ягыннан төрләре: аналитик иярчен җөмләләр, синтетик иярчен җөмләләр, иярченле кушма җөмләләрнең синонимлыгы һәм рус телендә бирелеш формалары;<br>-Иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре: иярчен ия җөмлә, иярчен хәбәр җөмлә, иярчен тәмамлык җөмлә, иярчен аергыч җөмлә;<br>-Иярчен хәл җөмләләр: иярчен вакыт җөмлә, иярчен урын җөмлә, иярчен рәвеш җөмлә, иярчен күләм җөмлә, иярчен максат җөмлә, иярчен шарт җөмлә, иярчен кире җөмлә, иярчен кереш җөмлә,;мәгънә һәм төзелеше ягыннан төрле булган иярченле кушма җөмләләрне сөйләмдә дөрес куллану, иярченле кушма җөмләләрне үзгәртеп кору;<br>-Катлаулы кушма җөмләләр: күп тезмәле кушма җөмлә, күп иярченле кушма җөмләләр, тиңдәш, тиңдәш түгел бер-бер артлы ияртүле һәм берничә төр ияртүле  күп иярченле кушма җөмләләр; катнаш кушма җөмләләр турында төшенчә; |
| 3 | Текст һәм пунктуация | 4 | -Текст синтаксисы: тезем, чит сөйләмле текст, туры сөйләм янында тыныш билгеләре;<br>-Пунктуация: җөмләнең төзелеше, мәгънәсе, интонация һәм тыныш билгеләре; нокта, сорау, өндәү билгеләре куела торган очраклар; күп нокталар һәм куштырнаклар куелу очраклары; өтер куелу очраклары; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | нокталы өтер, ике нокта куелу очраклары; сызык, җәяләр куелу очраклары; |
| 4 | Синтаксис һәм пунктуацияне гомумиләштереп кабатлау. Җөмләләргә синтаксик анализ ясау. | 4 | |
| 5 | Стилистика һәм сөйләм культурасы | 12 | -Әдәби һәм язма сөйләм стильләре турында төшенчә; язма сөйләм стильләре; синонимнарның сөйләм оештырудагы роле, стилистик хаталар; сөйләм культурасы, әдәби тел нормалары; |
| 6 | 5 – 9 нчы сыйныфларда үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау | 8 | -Фонетика, орфоэпия, графика һәм орфография; лексикология;сүз төзелеше һәм сүз ясалышы; морфология, синтаксис һәм пунктуация |
| 7 | Бәйләнешле сөйләм үстерү | 14 | |
| | Барлыгы | 68 | |

| чирек | I | II | III | IV | еллык |
|---|---|---|---|---|---|
| татар теле | 18 | 14 | 20 | 16 | 68 |

**Практик өлеш**

| | 1 чирек | 2 чирек | 3 чирек | 4 чирек | Елга |
|---|---|---|---|---|---|
| Диктант | 1 | 1 | | 2 | 4 |
| Сочинение | | 2 | 2 | | 4 |
| Изложение | 1 | | 1 | | 2 |
| Тест | 3 | | 1 | 2 | 6 |

**2015 – 2016 нчы уку елына арадаш аттестация. Үткәрү формасы: тест**

**Календарь тематик план (9 сыйныф, татар төркеме)**

| № | Дәрес темасы | Сәг саны | Дәрестә кулланган эш төрләре | Белем тикшерү төре | Көтелгән нәтиҗәләр | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | План | Факт |
| 1 | Синтаксис буенча 8 класста үткәннәрне кабатлау. | 1 | Кабатлау, белемнәрне системага салу, күнегүләр эшләү | | Әйтү максаты ягынна җөмлә төрләрен, җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен, тиңдәш кисәкләрне, аерымланган кисәкләре, модаль кисәкләре һәм алар янында тыныш билгеләренең куелышын искә төшерү | | |
| **34сәг.Кушма җөмлә төрләре** | | | | | | | |
| 2 | Кушма җөмлә һәм кушма җөмлә синтаксисы буенча гомуми төшенчә.. | 1 | Яңа материал белән таныштыру, күнегүләр эшләү | Кагыйдә | Кушма җөмләнең ике яки берничә гади җөмләдән торуы, гади җөмләдән төзелешләре белән аерылуы. | | |
| 3 | Кушма җөмлә төзүче җөмләләрнең бер-берсенә бәйләнеше | 1 | Кушма җөмлә төзүче җөмләләрнең бер-берсенә бәйләнешен анлату, күнегүләр эшләү | | Кушма җөмләгә берләшкән гади җөмләнең форма ягыннан үзара тыгыз бәйләнгән булулары, түбәндәге чаралар (теркәгеч, мөнәсәбәтле сүз, интонация, кушымча, бәйлек һәм бәйлек сүз, янәшәлек,) ярдәмендә | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | бәйләнүләре | | |
| **Тезмә кушма җөмлә** | | | | | | | |
| 4 | Тезмә кушма җөмлә. Тыныш билгеләре.Бәйләүче чаралары | 1 | Кушма җөмлә эчендәге гади җөмлә -ләрнең үзара тезү һәм ияртү юлы белән бәйләнүләре | Тест | Үзара тезү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган кушма җөмләләрнең тезмә кушма җөмлә дип аталуы.Теркәгечле һәм теркәгечсез кушма җөмләләр булуы | | |
| 5 | Кереш контроль эш. Диктант."Казантау" | 1 | | | | | |
| 6 | Теркәгечле тезмә кушма җөмләләр.<br>Алар янында тыныш билгеләре | 1 | Теркәгечле кушма җөмләләрнең үзара җыючы, каршы куючы, бүлүче теркәгечләр ярдәмендә бәйләнү | | теркәгечле тезмә кушма җөмлә<br>эчендәге гади җөмләләр бер-бер берсеннән өтер белән аерылулары | | |
| 7 | Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр. Алар янында тыныш бигеләре | 1 | Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрне бәйли торган чаралар: санау интона -циясе, каршы кую интонациясе,күнегүләр эшләү | | Санау интонациясе ярдәмендә бер үк вакытта булган, бер-бер артлы килгән һәм төрле вакытта булган күренешләрнең саналып күрсәтелүе; каршы кую интонациясе ярдәмендә күренешләр бер-берсенә каршы куелулары; бер-берсеннән өтер белән аерылулары, гади җөмләләрнең үз эчендә өтер булса, андый җөмләләр үзара нокталы өтер белән | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | аерылулары, кискен каршы куюны һәм вакыйгаларның кинәт аерылышуын белдергән җөмләләр арасында сызык куела | | |
| 8-<br>9 | Кабатлау. Кушма җөмләләр. Кабатлау. Тезмә кушма җөмләләр. Алар янында тыныш билгеләре. | 2 | Кагыйдәләр белән эш. Җөмлә тикшерү. | Тест . | Тезмә кушмалар турында алган<br>белемнәрне ныгыту. | | |
| | | | **Иярченле кушма җөмләләр** | | | | |
| 10-<br>11 | Иярченле кушма җөмлә: баш һәм иярчен җөмлә.Иярчен җөмлә-не мәгънә һәм төзелеш ягыннан төркемләү. | 2 | Яңа материал белән таныштыру, күнегүләр эшләү | Кагыйдә | Үзара ияру юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган кушма җөмлә иярченле кушма җөмлә дип аталу, ияреп килгән җөмлә-иярчен дип, ияртеп килгәне-баш җөмлә дип аталуы. Баш җөмләдән иярчен җөмләгә сорау куелу. Иярчен җөмләләрнең иярчен ия, иярчен хәбәр, иярчен тәмамлык, иярчен аергыч, иярчен кереш һәм иярчен хәл җөмләләргә бүленүе. Төзелешләре ягыннан , ягъни бәйләүче чараларның иярчен җөмләнең хәбәре составында булу-булмавыннан чыгып. иярчен җөмләләр аналитик һәм синтетик төрләргә | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | бүленүләре. | | |
| 12-13 | Иярченле кушма җөмлә төзелеш ягыннан төр-е: аналитик иярчен җөмлә, синтетик иярчен җөмлә. Иярченле кушма җөмлә-нең синонимлыгы һәм рус телендә бирелеш формалары | 2 | Яңа материал белән таныштыру, күнегүләр эшләү | | Баш җөмләгә үзенең хәбәре составында тормый торган чаралар ярдәмендә ияргән җөмләнең аналитик җөмлә дип аталуы, бәйләүче чаралары өч төрле булуы: иярчен теркәгечләр һәм теркәгеч сүзләр, мөнәсәбәтле сүзләр, көттерү интонациясе, мөнәсәбәтле сүзләр, ике төрле тыныш билгесе куелу-өтер һәм ике нокта. Баш җөмләгә үзенең хәбәре составындагы чаралар ярдәмендә ияргән җөмләнең синтетик җөмлә дип аталуы, бәйләүче чаралары өч төрле булуы: кушымчалар, бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр, янәшә тору, бер төрле тыныш билгесе куелу. | | |
| 14 | **Изложение “Туган ягым табигате”.** | 1 | | Изложение | | | |
| | | | **Иярченле кушма җөмләләр** | | | | |
| 15 | Изложениегә анализ. . Иярчен ия җөмлә | 1 | Иярчен ия җөмлә төшенчәсен аңлату күнегүләр эшлә | | Иярчен ия җөмләнең я баш җөмләнең иясе урынында килүе, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән ияне ачыклавы; | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | аналитик һәм синтетик төрләре булуы; рус телендә придаточные изъяснительные предложения дип аталуы | | |
| 16 | Иярчен хәбәр җөмлә<br>Беркетмә язу | 1 | Иярчен хәбәр җөмлә төшенчәсен аңлату күнегүләр эшлә | Тест | Иярчен хәбәр җөмләнең я баш җөмләнең хәбәре урынында килүе, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән хәбәрне ачыклавы; бары тик аналитик булуы; рус телендә придаточные изъяснительные предложения дип аталуы | | |
| 17 | Иярчен тәмамлык җөмлә | 1 | Яңа материал белән таныштыру, күнегүләр эшләү | | Иярчен тәмамлык җөмләнең я баш җөмләнең иясе урынында килүе, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән тәмамлыкны ачыклавы; аналитик һәм синтетик төрләре булуы; рус телендә придаточные изъяснительные предложения дип аталуы | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 18 | Иярчен аергыч җөмлә | 1 | Иярчен аергыч җөмлә төшенчәсен аңлату , күнегүләр эшләү . Белдерү язарга өйрәнү. | | Иярчен ия җөмләнең я баш җөмләнең аергычы урынында килүе, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән аергычны ачыклавы; аналитик һәм синтетик төрләре булуы; рус телендә придаточные определительные предложения дип аталуы | | |
| | **2 чирек – 14 сәг** | | **Иярчен хәл җөмләләр** | | | | |
| 19<br>20 | Иярчен вакыт җөмлә.Иярчен урын җөмлә | 2 | Иярчен вакыт җөмлә һәм иярчен урын җөмлә б/н таныштыру, күнегүләр эшләү | Кагыйдә | Иярчен вакыт җөмләнең я баш җөмләнең вакыт хәле урынында килүе, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән вакыт хәлен ачыклавы; аналитик һәм синтетик төрләре булуы; аналитик и. җ. баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә, синтетик и.җ. баш җөмләгә кайбер килеш һәм хәл фигыль кушымчалары ярдәмендә бәйләнүе. Иярчен урын җөмләнең я баш җөмләнең урын хәле урынында килүе, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән урын хәлен ачыклавы; аналитик | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | һәм синтетик төрләре булуы; аналитик и. ж. баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә, синтетик и.ж. баш җөмләгә кайбер килеш кушымчалары ярдәмендә бәйләнүе. | | |
| 21 | Сочинение”Хыял”. | 1 | Бсү ГИА га хәзерләнү | сочинение | | | |
| 22<br><br>23 | Сочинениегә анализ . Иярчен рәвеш җөмлә.<br>Иярчен күләм җөмлә | 1<br><br>1 | Иярчен рәвеш җөмлә.<br><br>иярчен күләм җөмлә б/н таныштыру, күнегүләр эшләү | кагыйдә | Иярчен рәвеш җөмләнең я баш җөмләнең рәвеш хәле урынында килүе, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән рәвеш хәлен ачыклавы; аналитик һәм синтетик төрләре булуы; аналитик и. ж. баш җөмләгә гүя теркәгече, мөнәсәбәтле сүзләр һәм –мыни/-мени кисәкчәсе ярдәмендә, синтетик и.ж. баш җөмләгә –ча/-сә, -дай/-дәй хәл фигыль кушымчалары , кебек, шикелле, сыман, төсле, килеш, хәлдә, итеп бәйлекләре һәм бәйлек сүзләре ярдәмендә бәйләнүе. Иярчен күләм җөмләнең я баш җөмләнең күләм хәле урынында килүе, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | белән бирелгән күләм хәлен ачыклавы; аналитик һәм синтетик төрләре булуы; аналитик и. ж. баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә, синтетик и.ж. баш җөмләгә төрле кушымчалары һәм дәрәҗәдә, кадәр бәйлек сүзләр ярдәмендә бәйләнүе. | | |
| 24<br>-25 | Иярчен сәбәп җөмлә.<br>Иярчен максат җөмлә | 2 | Яңа материал белән таныштыру, күнегүләр эшләү, гариза язарга өйрәнү. | | Иярчен сәбәп җөмләнең я баш җөмләнеңсәбәп хәле урынында килүе, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән сәбәп хәлен ачыклавы; аналитик һәм синтетик төрләре булуы; аналитик и. ж. баш җөмләгә чөнки теркәгече, мөнәсәбәтле сүзләр һәм көттерү интонациясе ярдәмендә, синтетик и.ж. кайбер килеш кушымчалары, хәл фигыль кушымчалары , күрә, сәбәпле, аркасында бәйлекләре һәм бәйлек сүзләре ярдәмендә бәйләнүе. Иярчен максат җөмләнең я баш җөмләнең максат | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | хәле урынында килүе, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән максат хәлен ачыклавы; аналитик һәм синтетик төрләре булуы; аналитик и. җ. баш җөмләгә шуның өчен, моның өчен мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә, синтетик и.җ. баш җөмләгә төрле өчен бәйлеге, дип бәйлек сүзе ярдәмендә бәйләнүе. | | |
| 26 | **Сочинение.”Ятим”** | 1 | Бсү ГИА га хәзерләнү | сочинение | | | |
| 27 | Сочинениегә анализ. Иярчен шарт җөмлә. | 1 | Иярчен шарт җөмлә белән таныштыру, күнегүләр эшләү | | Иярчен ия җөмләнең я баш җөмләнең шарт хәле урынында килүе, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән шарт хәлен ачыклавы; аналитик һәм синтетик төрләре булуы; аналитик и. җ. баш җөмләгә шулай булса, алай булса, югыйсә мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә, синтетик и.җ. шарт фигыль кушымчасы һәм исә, икән сүзләре ярдәмендә бәйләнүе. | | |
| 28 | Иярчен кире җөмлә. | 1 | Иярчен кире җөмлә белән таныштыру, күнегүләр эшләү | Ышанычнамә | Иярчен кире җөмләнең я баш җөмләнең кире хәле урынында килүе, я баш | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ышанычнамә язу | | җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән ктре хәлне ачыклавы; аналитик һәм синтетик төрләре булуы; аналитик и. җ. баш җөмләгә шулай да, алай да, шулай булса да, шуңа карамастан мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә, синтетик и.җ. шарт хәл фигыль кушымчалары, хәл фигыльнең –гач,-гәч, -ып, -еп кушымчалары һәм –да,-дә кисәкчәсе, карамастан бәйлек сүзләре ярдәмендә бәйләнүе. | | |
| 29 | **Ике компонентлы һәм катлаулы кушма җөмләләр.** | 1 | Иярчен кереш җөмлә белән таныштыру, күнегүләр эшләү | | Баш җөмләнең яисә аның берәр кисәгенең эчтәлегенә сөйләүченең мөнәсәбәтен белдергән, аңа аңлатма рәвешендә килгән җөмлә иярчен кереш җөмлә дип аталуы; аналитик төре генә булуы. Кереш җөмләләрнең ике төре булуы: баш җөмләгә гомумән карый торган кереш җөмләләр, баш җөмләдәге берәр кисәкнең эчтәлегенә карагае кереш җөмләләр. | | |
| 30 | **Контроль диктант.Иярчен** | 1 | | Диктант | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | **җөмлә. “Мәгариф”4/2013,26 бит.** | | | | | | |
| 31 | Диктантка анализ.Иярченле кушма җөмләләрне кабатлау | 1 | | | Иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау | | |
| 32 | Мәгънә һәм төзелеше ягыннан төрле булган иярченле кушма җөмлә-не сөйләмдә дөрес куллану, иярченле кушма җөмләләрне үзгәртеп кору<br><br>**3 чирек, 20 сәг.** | 1 | Яңа материал белән таныштыру, күнегүләр эшләү | | Эчтәлек тыңлаучыга тизрәк, җиңелрәк барып җитсен һәм сөйләм матуррак, аһәңлерәк булсын өчен, иярченле кушма җөмләнең төп мәгънәсенә зыян китермичә, бер төрле аналитик җөмләне икенче төр аналитик җөмләгә , бер төр синтетик җөмләне аның башка төренә, яки аналитик төрне синтетик төргә һәм киресенчә үзгәртеп төзергә мөмкинлеге | | |
| | | | **Катлаулы кушма җөмләләр** | | | | |
| 33 | Күп тезмәле кушма җөмлә | 1 | Күп тезмәле кушма җөмлә белән таныштыру, күнегүләр эшләү | | Үзара тезүле бәйләнештәге икедән артык гади җөмләдән торган катлаулы җөмлә күп тезмәле кушма җөмлә дип аталуы. | | |
| 34 | **Контроль изложение . ”Үсмер чак хатирәсе”. Мәгариф, 4/2004, 21 бит.** | 1 | БСҮ | Изложение | | | |
| 35-36 | Изложениегә анализ. Күп иярченле кушма җөмләләр. Аларга анлиз ясау тәртибе | 2 | Яңа материал белән таныштыру, күнегүләр эшләү | Җөмләләр өстендә эш (10 мин) | Үзара ияртүле бәйләнештәге икедән артык гади җөмләдән торган катлаулы җөмлә күп иярченле кушма җөмлә дип | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | аталуы. Төзелешләре ягыннан күп иярченле кушма җөмләләрнең дүрт төре булуы: тиңдәш ияртүле, тиңдәш түгел ияртүле, бер-бер артлы ияртүле, берничә төрле ияртүле. | | |
| 37-<br>38 | Катнаш кушма җөмләләр турында төшенчә.<br>Катнаш кушма җөмләләргә синтаксик анлиз ясау тәртибе. | 1<br><br><br>1 | Катнаш кушма җөмләләр белән таныштыру, күнегүләр эшләү | Кагыйдәләрне куллану.<br>Җөмлә тикшерү | Гади җөмләләрне үзара тезү юлы белән дә, ияртү юлы белән дә бәйләнгән катлаулы кушма җөмлә катнаш кушма җөмлә дип аталу. | | |
| 39 | **Сочинение “Бүре”.** | 1 | Бсү ГИА га хәзерләнү | Сочинение | | | |
| 40<br>41<br>42 | Кабатлау. Иярченле кушма җөмләләр.<br>Кабатлау. Күп тезмәле кушма җөмләләр.<br>Кабатлау. Катнаш кушма җөмләләрне кабатлау. | 1<br>1<br>1 | Белемнәрне йомгаклау, системага салу, күнегүләр эшләү | Җөмләләр өстендә эш . | Кушма җөмләләрнен төрләрен аера белү һәм тикшерә белү. | | |
| | | **4 сәг.** | **Текст синтаксисы һәм пунктуация** | | | | |
| 43 | Текст турында гомуми төшенчә. | 1 | Текстларның  функциональ яктан бүленешен тикшерү. | Текстан синтаксик берәмлекләрне ачыклау. | Мәгънәви яктан төгәлләнгән, билгеле бер рәвештә оешкан тоташ сөйләм текст дип аталуы. Функциональ яктан текстның өчкә бүленүе: хикәяләү, тасфирлау, фикерләү | | |
| 44 | Туры һәм кыек сөйләм | 1 | Туры һәм кыек сөйләм белән таныштыру, күнегүләр эшләү | | Сөйләм ике төрле була: телдән сөйләм һәм язма рәвештә була. Текста | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | сөйләүченең сүзен автор сөйләме, башка кеше сүзләрен – чит сөйләм диләр. Үзгертелмичә кулланылган сөйләм – туры сөйләм  дип атала. Үзгәртелгәне – кыек сөйләм дип атала | | |
| 45<br><br>46 | Туры сөйләм янында тыныш билгеләре.<br>Кыек сөйләм янында тыныш билгеләре. | 1<br><br><br>1 | Җөмләләрне дөрес интон. белән укып, туры сөйләм , кыек сөйләм янындагы тыныш билгеләрен аңлату күнекмәләрен үстерү өстендә эш. Схемалар төзү. | Бирелгән схемага туры китереп, мисаллар уйлау. | Монолог, диалог, цитата төшенчәләрен аңлау.  Туры һәм, кыек сөйләмдә тыныш билгеләрен дөрес итеп куя белү. | | |
| 47 | **Сочинение.”Сабантуй”** | 1 | ГИА га хәзерләнү | Сочинение | | | |
| | | **12 сәг.** | **Стилистика һәм сөйләм культурасы** | | | | |
| 48 | Сочинениегә анализ. Әдәби һәм язма сөйләм стильләре турында төшенчә. | 1 | Яңа материал белән таныштыру, күнегүләр эшләү | ГИАга әзерлек | Телдәге стильләрне һәм аларга хас тел-стиль чараларын өйрәнә торган фәннең стилистика дип аталуы.Телдә киң кулланыла торган сүзләрнең стилистик битараф сүзләр дип йөртелүе татар телендә 5 стиль булуы: әдәби стиль, публицистика стиле, фәнни стиль, рәсми стиль, сөйләмә стиль | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 49 | Язма сөйләм стильләре. Эпистоляр стиль. | 1 | Язма сөйләм стильләре белән таныштыру, күнегүләр эшләү | | Язма сөйләм стильләре б/н танышу. Эпистоляр стиль өстендә эш | | |
| 50 | **Тест (ГИА, А,С өлеше).** | 1 | ГИА га хәзерләнү | Тест Ачык дәрес. | | | |
| 51 | Тестларга анализ. Язма сөйләм стильләре.Фәнни стиль | 1 | Яңа материал белән таныштыру, күнегүләр эшләү | | Фәнни стильдә төрле фәннәр буенча мәкаләләр, китаплар, дәреслекләр язылганын белү | | |
| 52 | Язма сөйләм стильләре. Рәсми стиль<br><br>**4 чирек, 16 сәг.** | 1 | Рәсми стиль белән таныштыру, күнегүләр эшләү | | Закон, юридик эш кәгазьләре, гариза,акт, рәсми хат, белдерү язылганын белү | | |
| 53 | Публицистик стиль | 1 | Яңа материал белән таныштыру, күнегүләр эшләү | | Газета-журнал мәкаләләре язылганын белү | | |
| 54 | Сөйләмә стиль | 1 | Әдәби стиль белән таныштыру, күнегүләр эшләү | | Сөйләмә стиль – матур әдәбият теле икәнен белү | | |
| 55 | Сөйләмә һәм язма стильләрнең Лексик –грамматик үзенчәлекләре. | 1 | Сөйләмә һәм язма стильләрнең Лексик –грамматик үзенчәлекләрен ачыклау өстендә эш.. | Текстның нинди стильгә каравын ачыклау. | Предметларны тасвирлаганда аерманы ачыклый белү. | | |
| 56 | Стилистик хаталар; | 1 | Стилистик хаталар белән таныштыру, күнегүләр эшләү | | Җөмләдә сүзләрнең дөрес куелмавы аркасында әдәби тел нормаларының бозылуы, төрлечә уйларга юл | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | калдырылуы, аларны кисәтү чаралары. | | |
| 57 | **Диктант”Мәгариф”4/2008,17б ит.** | 1 | диктант | | | | |
| 58 | Диктантка анализ. Сөйләм культурасы, әдәби тел нормалары;<br>Калькалар. | 1 | Дөрес,ачык. Эзлекле, сәнг-ле, аһәңле, җыйнак, матур яңгырашлы сөйләм турында әңгәмә. Калькалар.Практик эшләр. | Текст тәрҗемә итү. | Сөйләм культурасы-кешенең гомуми культурасының бер би<br>лгесе булу, матур итеп әдәби телдә сөйләшкән кешенең сүзе генә тыңлаучыга үтемле булу. | | |
| 59 | Әдәби сөйләмнең төп билгеләре. | 1 | Дөрес,ачык. Эзлекле, сәнг-ле, аһәңле, җыйнак, матур яңгырашлы сөйләм турында әңгәмә. Практик эшләр. | Әңгәмәдәшнең сөйләменә характеристика бирү. | Матур сөләм күнекмәләренең үсүе. | | |
| 60 | **Тест (ГИА, А,С өлеше)** | 1 | ГИА га хәзерләнү | Тест | Тел белеме буенча белемнәрнең камилләшүе. | | |
| 61 | Стилистика һәи сөйләм культурасын кабатлау. | 1 | Белемнәрне йомгаклау, системага салу, текстлар белән эш. | Текстан стилистик хаталарны табу. | Сөйләм культурасы-кешенең гомуми культурасының бер билгесе икәненә төшенү. | | |
| | | **5с.** | **5 – 9 нчы сыйныфларда үзганнарны гомумиләштереп кабатлау** | | | | |
| 62 | Тестларга анализ.Фонетика, орфоэпия, графика һәм орфография | 1 | Белемнәрне гомуми-реп кабатлау, күнегүләр эшләү | | Фонетика, орфоэпия, графика һәм орфографияне кабатлау | | |
| 63 | **Арадаш аттестация эше.<br>Тест (ГИА, А өлеше).** | 1 | Белемнәрен тикшерү | ГИАга әзерлек. | | | |
| 64 | Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы | 1 | Белемнәрне гомуми-реп кабатлау, күнегүләр | | Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы кабатлау | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | эшләү | | | | |
| 65 | **Контроль диктант”Мәгариф”,11/2009,27 б.** | 1 | Белемнәрен тикшерү | Диктант | Грамоталылыкның үсүе. | | |
| 66-67 | Морфология | 1<br>1 | Сүз төркемләрен кабатлау, күнегүләр эшләү | Текстан сүз төркемнәрен билгеләү. | Исем, сыйфат, фигыль, сан, алмашлык, ревеш темасын кабатлау | | |
| 68 | Синтаксис һәм пунктуация. | 1 | Күнегүләр өстендә эш. | Җөмлә тикшерү. | | | |

**Арадаш аттестация эше (тест)**

**Текстны укыгыз һәм 1-20 нче биремнәрне үтәгез.**

**Әни**

**(1)Көзнең пычрак, ямьсез көннәреннән берсе иде. (2)Карт имәннәр, шәрәләнгән гәүдәләрен сыкратып, авыр ыңгырашалар. (3)Имәннәрнең күз яшедәй берән-сәрән сары яфраклары очкалый.**

**(4)Без әни белән урманга корыган ботаклар җыярга килдек.(5)Басу капкасыннан чыккач, кызыл яр кырыенда авыру кешедәй саламга төренеп утырган иске өебезне җылыту өчен, без көн саен шулай җилкә белән утын ташыйбыз. (6)Кышын да шулай, көзен дә.**

**(7)Әнинең кулында озын ыргак. (8)Ул аны корыган ботакка эләктерә дә, без аңа икәүләп асылынабыз.(9) Ботак шартлап сынгач, башка төшмәсен дип, читкә тайпылабыз.**

**(10)Шулай маташа торгач, көн дә кичекте. (11)Урманга кичке караңгы сирпелә башлады. (12)Ә безнең кайтасы җир ярыйсы ук ерак.**

**(13)Мин үзем күтәрәсе бәйләмне киндерә белән бәйләдем дә әнигә булыштым. (14)Ул үзенә иң авыр ботакларны җыйган. (15)Шуның өстенә тагын миннән калган чыбык-чабыкны да үз бәйләменә сыйдырмакчы булып азаплана.**

**— (16)Җитәр инде, әни, бик авыр була,— дигәч, күтәрелеп карады. (17)Шул сүзне әйткәнгә күңеле булгандыр, күрәсең, елмаерга итте.**

**— (17)Нишлим соң, улым! (18)Инде бер килгәч, күбрәк кайтсын дим. (19)Көннең-көн саен утын ташып син дә бик йөдәдең, әллә берәр көн килми калырбызмы диюем иде,— диде.**

**(20)Аның бәйләменнән бер-ике ботакны үземә алырга сузылгач, ул аларны бирмәде.**

**— (21)Инде мин чирлисен чирләгән, улым, мине кайгыртма. (22)Син дөнья көтәсе кеше, гарип булып калма... сеңелләрең дә синең өстә...— (23)Әни сүзен әйтеп бетермәстән кинәт туктады, аркамнан сыйпап:**

**— Синең буыннарың ныгымаган әле<…> шуңар гына әйтәм,— дип төзәтеп куйды.**

**1**. Кайсы җөмлә түбәндәге сорауга җавап бирә?
*Тышта нинди көн?*

1. **Нишлим соң, улым!**
2. **Көзнең пычрак, ямьсез көннәреннән берсе иде.**
3. **Без әни белән урманга корыган ботаклар җыярга килдек.**
4. **Аның бәйләменнән бер-ике ботакны үземә алырга сузылгач, ул аларны бирмәде.**

**2. Чагыштыру** булган җөмләне табыгыз.

1 **Көзнең пычрак, ямьсез көннәреннән берсе иде.**

2 **Имәннәрнең күз яшедәй берән-сәрән сары яфраклары очкалый.**

3 **Без әни белән урманга корыган ботаклар җыярга килдек.**

4 **Кышын да шулай, көзен дә.**

Җавап:___________________

**3**. 14нче җөмләдәге **әйтелеше язылышына** туры килмәгән сүзне табыгыз.
Җавап:___________________

**4.** 17нче җөмләдәге **әйтелеше язылышына** туры килмәгән сүзне табыгыз.
Җавап:___________________

**5.** . 4 нче җөмләдән *“кипкән”* сүзенә **синоним** булган берәмлекне табып языгыз.
Җавап:___________________

**6.** 14нче җөмләдән **баш кисәкләрне** табып языгыз.
Җавап:_____________________

**7.**1 -3 нче җөмләләр арасыннан **тиңдәш кисәкләр** булган җөмләнең номерын языгыз.
Җавап:_____________________

**8.** 14-16нчы җөмләләр арасыннан **туры сөйләмле** җөмләнең номерын языгыз.
Җавап:_____________________

**9.Аерымланган хәлгә** бәйле куелган өтернең номерын языгыз.
***Карт имәннәр, (1) шәрәләнгән гәүдәләрен сыкратып,(2) авыр ыңгырашалар.(3)***

Җавап:____________________

**10. Эндәш сүзгә** бәйле куелган **тыныш билгесенең** номерын языгыз.

**Җитәр инде,(1) әни, (2) бик авыр була,(3) — дигәч, (4)күтәрелеп карады.(5)**

Җавап:____________________

**11.**2нче җөмләдә ничә хәбәрлек бар?Җавапны сан белән языгыз.

Җавап:________________

**12.** . 23 нче җөмләдә <…> тамгасы урынына кайсы **тыныш билгесе** куелырга тиеш? Җавапны сүз белән языгыз.

**13**. 18-20 нче җөмләләр арасыннан **инкяр** җөмләнең номерын билгеләгез.

Җавап:________________

**14.**Тиңдәш кисәкләргә бәйле куелган тыныш билгесенең номерын языгыз.

**Күзнең пычрак,(1) ямьсез күннәреннән берсе иде . (2)**

**15.**1 нче җөмләдән *"чиста"*сүзенә **антоним** булган берәмлекне табып языгыз.

Җавап:________________

**16.** 3 нче җөмләдән **сыйфатны** табып языгыз.

Җавап:________________

17**.**Калын хәрефләр белән бирелгән **фигыльнең төрен** языгыз.

*Син дөнья **күтәсе** кеше, гарип булып калма... сеңелләрең дә синең өстә...*

Җавап:________________

**18.**1 нче җөмләдән **ясалма сүзне** табып языгыз.

Җавап:________________

**19**. 8 нче җөмләдән [ ы ] авазы [ о ] лашып әйтелә торган сүзне табып языгыз.

Җавап:________________

**20.**8 нче җөмләдән **юнәлеш килеше** кушымчасы ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне табып языгыз

Җавап:______________________